ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ

---

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е К А Р А Р

«12» июль 2019 ел №69

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына элекке «Берёзка» бакчачылык җәмгыяте территориясенә кагылышлы үзгәрешләр кертү проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында хәбәр итү турында

Халыкка яшәү өчен уңайлы шартлар булдыру хокукларын саклау, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, җирдән файдалану һәм төзү Комиссиясе тәкъдим иткән «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 21 декабрендәге 25нче номерлы карары нигезендә эшләнгән Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү проектын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32, 33 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20нче статьясы, 2017 елның 1 февралендәге Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлаулары үткәрү турындагы Нигезләмәгә таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналау картасына элекке «Берёзка» бакчачылык җәмгыяте территориясен, әлеге территорияне фактта файдалануга туры китерү максаты белән-квартал чикләрендә индивидуаль торак төзелеше участогын Ж-4 территориаль зонасыннан (бакчачылык һәм яшелчәчелек зонасы) Ж-1 (шәхси торак йортлар төзү зонасы) зонасына үзгәртү буенча, үзгәрешләр кертү проектын карау буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү башлануы турында хәбәр итәргә.

2. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына 2019 елның 219 июленнән 22 сентябренә кадәр үзгәрешләр кертү проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрергә.

3. 2019 елның 19 июлендә «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегендә - Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Тукай урамы 7нче йорт, 2нче кат адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү проекты экспозициясен ачарга.

"Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегендә проект экспозициясе белән танышу вакыты: 9.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр һәм 14.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, дүшәмбедән җомгага кадәр.

Экспозиция барышында “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә экспозициягә килүчеләргә җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проект турында консультация бирүне оештырырга.

4. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү проектын рәсми сайтта http://Leninogorsk.tatarstan.ru “Шәһәр төзелеше. Лениногорск шәһәре җирдән файдалану файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре» бүлегендә 2019 елның 19 июленә кадәр урнаштырырга.

5. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү проектына кагылышлы тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен 2019 елның 19 июленнән 19 сентябренә кадәр Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә язмача рәвештә, электрон формада Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Интернет-кабул итү бүлмәсенә http://leninogorsk.tatarstan.ru адресы буенча яисә

җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җыелышы барышында телдән бирергә мөмкин.

6. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җыелышын 2019 елның 19 сентябрендә "Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге бинасында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Тукай урамы, 7нче йорт, 2 нче кат, 1нче кабинетта 16.00 сәгатьтә үткәрергә дип билгеләргә.

7. Җәмәгать тыңлаулары башлану турында әлеге хәбәрне Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://Leninogorsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, шулай ук «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегендәге, адресы: Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Тукай урамы, 7нче йорт, 2 нче каттагы мәгълүмат стендында бастырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы А. Н. Карасевка йөкләргә.

Р.Г. Хөсәенов

А.Н. Карасев
5-28-28